ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мирфатиха Закиева, д.47,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Мирфатыйх Зәкиев урамы, 47йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**№ 11** **22 июль 2024 ел**

**Сайлау участоклары территориясендә басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында**

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»гы 67-ФЗ санлы Федераль законның 54 маддәсендәге 7, 8, 10 пунктлары, 2004 елның 19 июнендәге «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, йөрешләр һәм пикетлар турында»гы 54-ФЗ санлы Федераль законның 10 маддәсенең 2 пукнты нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты К А Р А Р  Б И Р Ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә 2024 елның 08 сентябрендә җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары сайлауларын үткәргәндә теркәлгән кандидатларның сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар исемлеген расларга (1 нче кушымта);

2. Махсус урыннар бүлеп биргәндә түбәндәгеләргә игътибар итәргә:

- сайлаучыларга килү һәм танышу өчен урнаштырылган мәгълүматның уңай булуы;
- теркәлгән кандидатларның басма агитация материалларын урнаштыру өчен тигез һәм җитәрлек мәйдан;
- сайлау комиссияләренең мәгълүмати материалларын урнаштыру өчен җитәрлек мәйдан;

3. Объектларда махсус урыннар урнаштыру шартлары турындагы мәсьәләне аларның хуҗалары белән килештерергә;

4. Басма агитация материалларын урнаштыру өчен бүлеп бирелгән урыннарны һәм аларга якын территорияне санитар тотуны тәэмин итәргә.

5. Ютазы районы территориаль сайлау комиссиясенә басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннарның урнашу урыны турында мәгълүмат бирергә.

6. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatar.ru веб-адресы буенча Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга;

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев

2024 елның 22 июлендәге 11
санлы карарына 1 кушымта

# Урыннары күрсәтелгән басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен урыннар

## 2805 санлы сайлау участогы

**Сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен урыннар:**

1. Кәрәкәшле ав., Көчле-Елга ур., 13А йорт (“Чулпан” кибете, мәгълүмати такта)
2. Кәрәкәшле ав., Мирфатыйх Зәкиев ур., 42 йорт (“Җәүмәт” кибете, мәгълүмати такта)
3. Кәрәкәшле ав., Мирфатыйх Зәкиев ур., 24 йорт (Ютазы район кулланучылар җәмгыяте кибете, мәгълүмати такта)
4. Салкын-Чишмә ав., Фрунзе ур., 22А йорт (Ютазы район кулланучылар җәмгыяте кибете, мәгълүмати такта)
5. Ак-Чишмә ав., Ак-Чишмә ур., 16 йорт (Ширмедова М.Т. йортының коймасы(килешү буенча).

## 2806 санлы сайлау участогы

**Сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен урыннар:**

1. Урал бистәсе, Урал ур., 3А йорт (Ютазы район кулланучылар җәмгыяте кибете, мәгълүмати такта)
2. Урал бистәсе, Көнчыгыш ур., 1В йорт (“Нәбиуллин” КФХ механизаторлары йорты, мәгълүмати такта)